СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.12.2023 ел Баулы шәһәре №233

2024 елга Баулы муниципаль районы
муниципаль милкен хосусыйлаштыруның
Фаразлау планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнарына ярашлы, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елга Баулы муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фаразлау планын (программасын) 1-нче номерлы кушымтага ярашлы расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль район
Советының 2023 елның
14 екабрендәге 233 номерлы
карарына 1-нче номерлы
Кушымта

2024 елга Баулы муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы)

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елга Баулы муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнарына ярашлы эшләнгән.

1.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру, Баулы муниципаль районы милек структурасын оптимизацияләүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемен арттыруга юнәлдерелгән.

1.3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында» карарына ярашлы гамәлгә ашырыла.

## 2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. Баулы муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. 2023 елга Баулы муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фаразлау планына (программасына) кертелгән, хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.3. Муниципаль милектә булган муниципаль казна предприятиеләрен һәм акцияләрен хосусыйлаштыру 2024 елда планлаштырылмаган.

2.4. Хосусыйлаштыруның Фаразланган планы гамәлдә булганда, 2024 елда хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль милек исемлеге яңа күчемсез милек объектлары белән тулыландырылырга мөмкин.

2.5. 2024 елда муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш (1-нче номерлы таблица).

1-нче номерлы таблица

| № п/п | Объект атамасы | Урнашкан урыны (Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы) |
|---|---|---|
| 1 | Торак булмаган корылма-запас частьләр склады, 16:55:010308:56 кадастр номеры белән, гомуми мәйданы 466,6 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |
| 2 | Җир участогы, 16:55:010308:69 кадастр номеры белән, гомуми мәйданы 24 970,0 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |